**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-22, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬ-
НОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-22, факс 3-44-14

КАРАР ______________ 23.05.2024 ПР-87 ПОСТАНОВЛЕНИЕ № _____

**Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгына вакантлы муниципаль вазыйфаны биләүгә конкурс турында**

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы, «Актаныш муниципаль районында вакантлы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» Актаныш муниципаль районы Советының 2007елның 01 августындагы 17/04 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2024 елның 11 июнендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгының вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрергә.

2. Расларга:
- 1 нче кушымта нигезендә конкурс комиссиясе составы;
- 2 нче кушымта нигезендә конкурс уздыру шартлары;
- 3 нче кушымта нигезендә конкурс комиссиясе эше регламенты.

3. Кадрлар белән тәэмин итү секторы мөдиренә Актаныш мәгълүмат порталының рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкче
карарына __________ №-__
1 нче кушымта

**Конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Ильясов Р.А. | комиссия рәисе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Вахитов И.Р. | Комиссия рәисе урынбасары, муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Әнвәрова Д.М. | Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| Гилаева М.З. - | комиссия рәисе урынбасары, муниципаль район Советының оештыру бүлеге башлыгы; (килешү буенча) |
| Касыймова Д.Р.- | комиссия секретаре, кадрлар белән тәэмин итү секторы мөдире; |
| Мөхәммәтдинов И.Т. | комиссия әгъзасы, Башкарма комитетның юридик бүлеге башлыгы; |
| Сәрвәрова Н.Ф. | комиссия әгъзасы, Башкарма комитетның гомуми бүлеге башлыгы. |

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкче
карарына __________ №-__
2 нче кушымта

**Конкурсны үткәрү шартлары**

Дәгъвачыларга квалификация таләпләре:

1) «дәүләт һәм муниципаль идарә» белгечлеге буенча югары профильле белем яки:

муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфасы яисә мәгариф белгечлеге буенча, ул Башкарма комитетның социаль һәм агарту эше бүлеге башлыгы өчен бертигез кыймматле санала;

2) Башкарма комитетның социаль һәм агарту эшләре бүлеге башлыгы муниципаль вазыйфасы өчен белгечлек буенча кимендә ике ел эш стажы;

Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә гариза бирә, аңа түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

1) үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, 4 x 6 зурлыгындагы фотосурәт белән;

2) паспорт яисә аны алыштыручы документ күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

3) кирәкле һөнәри белем бирүне, эш һәм квалификация стажын раслый торган документлар:

- һөнәри белем турында, шулай ук, гражданның теләге буенча, өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирү турында документларның эш (хезмәт) урыны буенча нотариаль яисә кадрлар хезмәтләре тарафыннан таныкланган күчермәләр;

- гражданның хезмәт эшчәнлеген раслый торган хезмәт кенәгәсенең яисә башка документларның күчермәсе;

4) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яисә аны узуга каршы килә торган авыруы булмау турында документы;

5) авторлык эшләре (гражданин теләге буенча).

Конкурс (документлар конкурсы, әңгәмә, һөнәри компетенцияне бәяләү) уздырыла: 2024 елның 11 июнендә 10.00 сәгатьтә.

Гаризалар һәм конкурс документларын бирү срогы:

Конкурс үткәрү турында хәбәр басылганнан соң 20 көн эчендә.

Гаризалар һәм конкурс документларын бирү урыны: 423740, Актаныш ав., Ленин пр., 17, өченче кат, кадрлар секторы, тел./факс (85552) 3-44-25

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкче
карарына __________ №-__
3 нче кушымта

**КОНКУРС КОМИССИЯСЕНЕҢ ЭШ РЕГЛАМЕНТЫ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының социаль һәм агарту эшләре бүлегенең вакантлы муниципаль вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү максатларында конкурс комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә. Конкурс комиссиясе составы муниципаль район Башлыгы карары белән раслана.

1.2. Комиссия үз эшчәнлеген муниципаль район Башлыгының Башкарма комитетның социаль һәм агарту эшләре бүлеге баәлыгы вазифасына дәгъва кылучыларны билгеләү турындагы боерыгы чыкканчы алып бара;

1.3. Конкурсны уздырганда комиссия федераль, республика законнарына һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килми торган дәгъвачыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын куллана ала.

2. Комиссия утырышларын үткәрү тәртибе

2.1. Комиссия утырышы 2024 елның 11 июнендә 10.00 сәгатьтә уздырыла.

2.2. Утырышны комиссия рәисе яки аны алмаштыручы зат алып бара.

2.3. Комиссия конкурста катнашу өчен тапшырылган документларны карый, әңгәмәләр үткәрә, конкурста катнашучыларның һөнәри һәм оештыру сыйфатларын бәяли.

2.5. Комиссия утырышы, комиссия составының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

2.6. Комиссия карарлары комиссия әгъзаларыннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмәдә чагылдырыла.

Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

2.7. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган карар белән рәсмиләштерелә.

2.8. Комиссия карары кандидат катнашыннан башка кабул ителә.

2.9. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең конкурс җиңүчесен вакантлы вазыйфага билгеләү турында боерыгы чыгарыла һәм конкурс җиңүчесе белән хезмәт килешүе төзелә.